**СОВЕТ ТУРАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

2021 елның 19 мартыннан № 25

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегендә җирдән файдалану
һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге советы,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 30 маендагы 52 номерлы Турай авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 35 статьяның «Шәһәр төзелеше зонасы картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.».

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районы Интернет челтәрендә https://mendeleevsk.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән башлап үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр һәм депутат этикасы буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Турай авыл җирлеге башлыгы А.М. Рәхимова